КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декбрь г.Казань № 1294

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» 2006 ел, 29 апрель, 258 нче Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибе расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Федераль компенсация фондыннан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2007 ел, 18 июнь, 247 нче»;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 18 июнь, 247 нче карарыбелән расланган Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Федераль компенсация фондыннан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 06 июль, 453 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1294 нче карары белән расланды

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибе

1. Әлеге Тәртип хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне (алга таба – субвенцияләр) тоту кагыйдәләрен билгели.

2. Субвенцияләрне тоту әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган шәхси счетлар аша гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм субвенцияне финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алынганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына финанслауның чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым җәдвәлен тапшыра.

4. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары Казначылыктан финансларның чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым җәдвәлен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр акчасы исәбеннән җирлекләр бюджетларына күчерү өчен касса чыгымына гариза тапшыра.

5. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле исәпләүләрне дә кертеп, хәрби-исәп хезмәткәрләре хезмәтенә түләү;

бина арендасы өчен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһазлар, инвентарь, оештыру техникасы, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

6. Квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 7 саныннан да соңга калмыйча, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирле бюджетларның чыгымнары турында, аларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән форма буенча хәрби

комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә хисап тапшыра.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 нче числосыннан да соңга калмыйча Россия Федерациясе Оборона министрлыгына һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгына финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килешү буенча Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгели торган форма буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган субвенцияләр булган беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирле бюджетларның чыгымнары турында хисап тапшыра.

7. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субвенцияләрнең максатсыз файдаланган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

8. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирле бюджетларның финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субвенцияләр торган чыгымнарын гамәлгә ашыруны тикшереп тору Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләнә.

9. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирле бюджетлар чыгымнарын гамәлгә ашыру очрагында финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып субвенцияләр торган, әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән шартларны бозып, тиешле акчалар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә федераль бюджетка тапшыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына җибәрелә.

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбенә бирелгән һәм әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә федераль бюджет керемена кире кайтарылган акчаларны кире кайтаруны гамәлгә ашыра.